ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 67-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Н.М. Гафиятуллин, А.Р. Зарипов, М.Х. Сәлахов, И.В. Терентьева тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 67-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 18 апреле
№ 272-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Н.М. Гафиятуллин,
А.Р. Зарипов,
М.Х. Сәлахов,
И.В. Терентьева
тарафыннан кертелә

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«10 статья. **Республика укыту-методика берләшмәләре**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан үз эшчәнлекләрен, Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү системасында укыту-методика берләшмәләре турында типлаштырылган нигезләмәләрне исәпкә алып, шушы орган раслаган нигезләмәләргә таянып башкаручы гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү системасында республика укыту-методика берләшмәләре төзелергә мөмкин.

2. Республика укыту-методика берләшмәләре составына, үзләре теләп, педагог хезмәткәрләр, фәнни хезмәткәрләр һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм башка оешмаларның бүтән хезмәткәрләре, эш бирүчеләр һәм аларның берләшмәләре вәкилләре, федераль дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкилләре керә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2025 елның 11 мартыннан үз көченә кергән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 19 һәм 20 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 28 февралендәге 29-ФЗ номерлы Федераль закон белән мәгариф системасында федераль һәм региональ укыту-методика берләшмәләре төзү һәм аларның эшләве мәсьәләләре төгәлләштерелә, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органнары тарафыннан гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү системасында региональ укыту-методика берләшмәләрен төзү мөмкинлеге күздә тотыла. Шулай ук урта һөнәри белем бирү һәм югары белем бирү системасында укыту-методика берләшмәләре составына, үзләре теләп, эш бирүчеләр һәм аларның берләшмәләре вәкилләре, федераль башкарма хакимият органнары һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкилләре керә дип билгеләнә.

Шуңа бәйле рәвештә «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.